ГЛАВА
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

площадь Советская, д.14, г.Арск, 422000

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШЛЫГЫ

Совет мәйданы, 14 нче йорт, Арча шәһәре, 422000

Тел. (84366)3-11-33, факс (84366)3-01-33, 3-14-33. E-mail: archa@tatar.ru. www.arsk.tatarstan.ru

**Арча район Советы**

**КАРАРЫ**

**«19» сентябрь 2019 ел** **№275**

**Арча район Советының 2008 елның 27 декабрендәге 224 номерлы карары (2011 елның 4 июлендәге 57 номерлы, 2012 елның 17 маендагы 137 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 342 номерлы, 2016 елның 12 июлендәге 61 номерлы, 2017 елның 10 ноябрендәге 152 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Арча муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында**

"Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" Федераль законның 5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 2017 елның 1 июлендәге 155-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә һәм Арча районы Прокуратурасының 2017 елныың 28 сентябрендәге 02-08-02-83/17 номерлы ризасызлыгын карап, Арча район Советы КАРАР бирде:

1. Арча район Советының 2008 елның 27 декабрендәге 224 номерлы карары (2011 елның 4 июлендәге 57 номерлы, 2012 елның 17 маендагы 137 номерлы, 2015 елның 28 маендагы 342 номерлы, 2016 елның 12 июлендәге 61 номерлы, 2017 елның 10 ноябрендәге 152 номерлы карарлары редакциясендә) белән расланган Арча муниципаль районының муниципаль милкен хосусыйлаштыру тәртибе турындагы Нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

А) Нигезләмәнең 1.4. пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.4. Муниципаль милекне сатып алучылар булып түбәндәгеләрдән кала төрле физик һәм юридик затлар торырга мөмкин:

- дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрдән тыш;

- "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законда каралган очраклардан кала, устав капиталында Россия Федерациясе, Россия

Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр өлеше 25 проценттан артып киткән юридик затлардан тыш;

- Россия Федерациясе Финанс министрлыгы тарафыннан расланган салым салуның ташламалы режимын бирүче һәм (яки) финанс операцияләре (офшор зоналар) (алга таба-офшор компанияләр) үткәргәндә Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә мәгълүмат ачуны һәм тапшыруны күздә тотмаган һәм үзләренең отышлы сатып алучылары, бенефициар хуҗалары һәм контрольдә тотучы затлар турында мәгълүмат ачмый һәм тапшырмый торган дәүләт яки территория теркәлү урыны булып торган юридик затлардан тыш.

"Контрольлек итүче зат" төшенчәсе 2008 елның 29 апрелендәге 57-ФЗ номерлы "Ил оборонасын һәм дәүләт иминлеген тәэмин итү өчен стратегик әһәмияткә ия булган хуҗалык җәмгыятьләренә чит ил инвестицияләрен гамәлгә ашыру тәртибе турында" Федераль законның 5 статьясында күрсәтелгән мәгънәдә кулланыла. "Отышлы сатып алучы" һәм "бенефициар хуҗа" төшенчәләре 2001 елның 7 августындагы 115-ФЗ номерлы "Җинаятьчел юл белән алынган керемнәрне легальләштерүгә (юдыртуга) һәм террорчылыкны финанслауга каршы тору турында" Федераль законның 3 статьясында күрсәтелгән мәгънәләрдә кулланыла.

Б) 1.7 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«1.7. Акционерлык җәмгыятьләре, җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр "Дәүләт һәм муниципаль милекне хосусыйлаштыру турында" 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә хосусыйлаштырыла торган устав капиталларында үз акцияләрен, өлешләрен сатып алучылар була алмый.»

В) 1.8 пунктның 8 нче абзацын түбәндәге редакциядә бирергә:

“- муниципаль унитар предприятиеләрне үзгәртеп корганда төзелгән коммерциячел булмаган оешмалар милкенә муниципаль милекне һәм дәүләт корпорацияләренә һәм коммерциячел булмаган башка оешмаларга Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектларының, муниципаль берәмлекләрнең мөлкәт кертеме буларак тапшырыла торган муниципаль милекне”.

Г) 6.1 пунктын түбәндәге редакциядә бирергә:

«6.1. Хосусыйлаштыруның түбәндәге алымнарын куллану күздә тотыла:

- унитар предприятиене акционерлык җәмгыятенә әйләндерү;
- унитар предприятиене җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә әйләндерү;
- муниципаль милекне аукционда сату;
- акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен махсуслаштырылган аукционда сату;
- муниципаль милекне конкурста сату;

- дәүләт милкендә булган акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен Россия Федерациясе территориясеннән читтә сату;

- дәүләт яки муниципаль милекне ачык тәкъдим кертү юлы белән сату;

- дәүләт яки муниципаль милекне бәяне игълан итмичә сату;

- дәүләт яки муниципаль милекне акционерлык җәмгыятьләренең устав капиталларына өлеш буларак кертү;

- акционерлык җәмгыятьләре акцияләрен ышанычлы идарә итү нәтиҗәләре буенча сату.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының Рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Арча муниципаль районының рәсми сайтында (arsk.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Арча район Советының икътисади үсеш, авыл хуҗалыгы һәм әйләнә-тирә мохитне саклау мәсьәләләре буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Арча муниципаль районы башлыгы,
район Советы рәисе И.Г.Нуриев

АРСКИЙ РАЙОННЫЙ СОВЕТ
АРЧА РАЙОН СОВЕТЫ